Индекс газеты - 52381

## Мәктәп тормышы

# «Дини тәрбия бирү - ул гаилә эше»

**Самар өлкә думасында мөһим мәсьәлә тикшерелде - мәктәпләрдә тәрбия эше буенча мөдир урынбасары итеп атакайны кую тәкъдиме. Бу тәкъдим белән Самар губерна Думасы депутаты Дмитрий Сивиркин чыккан иде. Әлеге тәкъдимне тикшерү җыелышына Талип хәзрәт Яруллин белән "Яктылык" мәктәбе мөдире Радик Газизов та чакырылган иде. Радик әфәнде бу очрашудан соң фикерләре белән уртаклашты.**

- Очрашуда Талип хәзрәт Яруллин тәрбия эше буенча мөдир урынбасарлары итеп атакайларны куюга катгый рәвештә каршы чыкты. Талип хәзрәт үзенең һәр фикерен дәүләт документларына таянып сөйләде. Фикер алышуда катнашкан депутатларга аның позициясе ошады. Утырышта шулай ук Самар өлкә мәгариф министрлыгыннан Владимир Классен да катнашты. «Ни өчендер чиркәү әһелләре административ ысулларга таянып эш итәргә тырыша. Социализм чорында административ юл белән идеологияне сеңдерергә тырышу нинди нәтиҗәләр биргәнен беләбез. Мәктәпләрдә диннәр тарихы, диннең мәдәни ягы балаларга җиткерелә. Аннары дин әһелләренә килеп үзләренең тәрбияви чыгышларын ясарга иреклек бар», - диде Владимир Классен.

- **Мәктәп мөдире һәм өч бала атасы буларак, үзегез нинди фикердә?**

- Мәктәп диннән азат булырга тиеш. Программа шулкадәр тыгыз ки, балага болай да читен. Әхлакый нормалар матур әдәбият аша да укытыла, ә әдәбият дәресләрен кыскартә баралар. Шәхсән фикерем: дини тәрбия - ул гаилә бурычы. Ата-аналар бер нәрсәгә төшенергә тиеш: татар гаиләсендә тәрбия ике өлештән торырга тиеш. Ул - татар халык педагогикасы һәм динебез Ислам таләпләре. Шул ике чыганакка таянып эш алып барган хәлдә, тәрбиядә уңыш көтеп була.

- **Радик әфәнде, әгәр бу ике компонент баланың ата-анасында булмаса?**



- Ата-анага җиң сызганып үз өстендә эшли башларга кирәк. Бүгенге көннең иң зур фаҗигасе шунда ки, кызлар әни булырга әзерләнми. Кызлар бай кияү эзли. Чит ил машинасы булсын, ташпулаты булсын, чит мәмләкәтләргә йөреп ял итәселәре килә. Ә бит өйләнергә җыенган маллы егетләребез булачак хатыннарына нинди таләпләр куйганын кызлар күзалларына да китерми. Гаилә корырга җыенганнарның күбесе хатынының татарча сөйләшә белүен, аш-су тирәсендә оста булуын, өйдә пөхтәлек булдыра торган кызларга өстенлек бирәләр. Егетләрнең бер катламы кызларның намаз укыуукымавы белән дә кызыксына.

- **Бу таләпләрнең асылы нидән гыйбарәт соң?**

- Һәр ир үз нәселенең дәвамлы булуын тели. Динебез Исламча яшәү - ул гаилә тотрыклыгы, милләт тотрыклыгы һәм Ватан тотрыклыгы.

- **Димәк, балаларга дин таләпләрен аңлатырга кирәк?**

- Хәзер һәр авылда, шәһәрләрдә мәчетләр эшли. Самарның үзендә генә дә алты мәчет. Барчасында да төрле яшьтәгеләр өчен Ислам дине сабаклары бирелә. Кил, язып, укы. Дистәләгән мөселман дәресләрне әле өйләрендә дә бирә. Укы гына. Русия мәгариф министрлыгы мәктәпләргә түбәндәге модульләрне тәкъдим итте: православие, ислам, иудаизм, буддизм диннәренең мәдәни нигезләре, дөньяви этика, барлык диннәрнең дә мәдәни нигезләре. "Яктылык" мәктәбендә ата-аналар Ислам диненең мәдәни нигезләрен сайлап алдылар һәм бу фән укытыла да. Самарның үзендә Ислам модуле тик "Яктылык" мәктәбендә генә. Самар шәһәр мәгариф департаменты тәкъдиме буенча Самар өлкә телевидениесе "Яктылык" мәктәбе турында тапшыру әзерләде. Мәктәптә дәрестән соң теләгән балаларга ата-аналары ризалык бирсә, гарәп хәрефләре өйрәтәбез. Хәзерге заманда гарәп дөньясы белән элемтәләр көчәя бара. Киләчәктә балада гарәп телен өйрәнү теләге тууы бар. Ә ул инде укый белә.

Икенче вариант. Еллар узу белән баланың Коръән укырга теләге тууы бар. Ә ул хәрефләрен инде таный. Яшь чакта баланың башы яхшы эшли, тик ул белем казанын сериаллар белән генә тутырмаска.

- **Мәктәпләрдә ирләр юк. Ирсез мәктәп тулы тәрбия бирә алмый. Бик еш Сезне егетләр чорнап алган була. Үзара сөйләшүләрдә нинди темаларга кагыласыз?**

- Егетләр миннән тартынмыйлар. Үзләрен иркен тоталар. Ачык сорауларга туры җавап бирәм. Ябык темалар юк.

- **Төп сүзегез нинди күчәр тирәсендә әйләнә?**

- Кешe гомеренең һәр чорын мин аларга ел фасыллары белән чагыштырам. Балачак үзенә бер сихри назлы төштәй. Үсмер чак - хисләр чоры. Хезмәт еллары - киерелеп тормыш арбасын тарту. Картларга карап торам да, асыл бабайларның тормыш тәҗрибәсенә сокланам. Ләкин дә, яшьлек - ул адәм гомеренең чәчкәсе һәм ул чәчкәдән матуррак берни юк.

- **Укучыларга иң кыска вәгазь сөйләргә кушсалар, нәрсә әйтер идегез?**

- Яшьлек уйнар өчен, күңел ачу өчен генә бирелмәгән, ә белем алу һәм һөнәр үзләштерер өчен Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән бер нигъмәттер.

*Шамил БАҺАУТДИН.*

## Истә калдырыгыз

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Замананы, вакытны сүкмәгез, чөнки заманаthe барлыкка китерүче Аллаһы Үзе».

## Языгыз, укыгыз, куаныгыз!



### Туганнар!

2013 елга "Ислам - Нур" гәҗитәсенә язылмаган булсагыз, декабрьнең 20сенә кадәр үзегез яши торган җирдә почта бүлегенә барып языгыз.

**Гәҗитәбезнең индексы - 52381.**

"Ислам - Нур" гәҗитәсен даими укып барсагыз, динебез Ислам турында гыйлемегез артыр.

"Ислам - Нур"ны даими укысагыз, татар халкының гореф-гадәтләрен үзләштерерсез.

Балалар тәрбияләүдә "Ислам - Нур" - беренче ярдәмче һәм акыллы киңәшче.

Балалар тәрбияләүдә авырлыклар килеп чыкса, безнең белән киңәшегез.

Эчегезне бушатып хатлар языгыз.

Җавабын гәҗиттә укырсыз.

Гәҗитә битендә язарга лаек, дип санаган кешегез булса, шалтыратып әйтегез, телефоннарыбыз: **932-58-67** һәм **8-937=656-76-16.**

"Ислам-Нур"га язылган булсагыз, якыннарыгызны бушлай тәбриклибез.

Адресыбыз: Самар шәһәре,

Стара Загора урамы, йорт саны, 54.

Самар Җамигъ мәсҗиде.

Редакция "Нур" мәдрәсәсе бинасында урнашкан.

Икенче кат, 26нчы һәм 29нчы бүлмәләр.

Сезләрне яратып көтеп калабыз.

## Сәламәтлек

# Ашказаны-эчәк авырулары. Ашказаны, үңәч ялкынсынганда, җәрәхәт булганда

**(Гастрит, язва желудка)**

***Чи бәрәңге***

*Ашказанында җәрәхәтле ялкынсыну булганда, уртача зурлыктагы чи бәрәңгене кыргычта кырып, суын сыгарга һәм ашарга 20-30 минут кала бер ай дәвамында көненә өч тапкыр эчәргә.*

**Иң элек микробларны үтерергә**

Соңгы вакытларда галимнәр арасында бу авыруны микроблар китереп чыгара диган фикер туды. Шуңа күрә, бәрәңге суын эчә башлаганчы, микробларны юк иту өчен, 15-20 көн дәвамында гөлбадран, әче әрем, пәйгамбәр тырнагы, канлы үлән, эт тигәнәге кебек үләннәр төнәтмәсе белән дәвалапарга кирәк.

***Чи кәбестә согы***

*Ашказанындагы җәрәхәтле ялкынсынуны ашарга 30 минут кала чи кәбестә согы эчеп тә дәвалыйлар.* Әмма, боларның кайсысы белән дәвалансаң да, ашказанының әчелеген исәпкә алырга туры килә. Ашказанының әчелеге аз булса, кәбестә һәм бәрәңге сокларына 1/3 өлеш булмә температурасындагы кайнаган су кушып эчәргә кирәк.

**Мүк җиләге белән сак булыгыз**

Мүк җиләге ашказаны һәм эчәк бизләренең эшләвен көчәйтә, азыкны сеңдерергә ярдәм итә. Әмма ашказанында әчелеге күп булган кешегә ул ярамый.

**Прополис**

*100 г прополисны 500 г атланмайда су эчендәге савытта эретергә. Күбеген җыеп ташлап, уртадагы чиста өлешен пыяла яисә эмаль савытта салкынга куярга. Ашарга 30 минут кала көнгә өч тапкыр бәрәр аш кашыгы кабарга.*

**Җитен орлыгы**

*Унике илле эчәк яисә ашказаны ялкынсынганда, ике аш кашыгы җитен орлыгын ике стакан кайнап торган суга салып, 30 минут төнәтергә һәм көнгә өч тапкыр, сөзмичә орлыгы белән бергә ач карынга яртышар стакан эчәргә.*

***Шәехҗан Фәния ХУҖАХМӘТ.***

**Уважаемые читатели!**

**В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.**

**Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.**

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.

**Ответственные за выпуск газеты:**
по организационно-финансовым вопросам - **Джавдят ШАРАПОВ,**
по духовно-просветительской части - **Наил СУЛЕЙМАНОВ.**

**Редактор -**
Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
Тел.: 8-937=65-67-616
**932-58-67 (раб.)**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 26.
**Адрес редакции и издателя:**
443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54.
Медресе «Нур», 2 этаж, кабинет 29.
E-mail: islam-nur@bk.ru

**Ответственный секретарь -**
Шамил БАГАУТДИН.
**Корреспондент -**
Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Верстка и дизайн -**
Рамил НУРЕТДИНОВ.
**Набор -** Гульназ САФИНА.
**Корректор -** Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**
***по установленному графику - 30 ноября 15:00***
***фактически - 30 ноября 15:00***

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**
**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ Тираж 2000.**
***Цена свободная.***
Рег. свидетельство
ПИ № ТУ63-00111
**Индекс газеты - 52381**